ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ПИСЬМЯНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ПИСМƏН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРƏМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның 30 октябре №3

**Лениногорск муниципаль районы Писмəн авыл җирлегенең Иске Писмəн торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һəм куллану мəсьəлəсе буенча гражданнар җыенын билгелəү турында**

«Россия Федерациясендə җирле үзидарə оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендəге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарə турында» 2004 елның 28 июлендəге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмəнавыл җирлеге» муниципаль берəмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендə, Лениногорск муниципаль районы «Писмəн авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.2023елның 18 ноябренə Лениногорск муниципаль районы Писмəн авыл җирлеге Иске Писмəн торак пунктында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һəм куллану мəсьəлəсе буенча гражданнарның җыенын 1 сəгать 00 минутка билгелəргə.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Сез 2024 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Писмəн авыл җирлеге Иске Писмəн торак пункты территориясендə яшəү урыны буенча теркəлгəн, балачактан инвалидлар, шулай ук I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һəм сугыш хəрəкəтлəре ветераннары; Бөек Ватан сугышы һəм сугыш хəрəкəтлəре ветераннарының тол хатыннары; көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һəр балигъ булган кешедəн алынган средстволарны җирле əһəмияттəге түбəндəге эшлəрне башкаруны хəл итүгə юнəлдерүгə 300 (өч йөз) сум күлəмендə билгелəү белəн килешəсезме:

Җирлек территориясен төзеклəндерү күрсəтелгəн кагыйдəлəргə ярашлы итеп, җирлек территориясен төзеклəндерү кагыйдəлəрен раслау, җирлек территориясен төзеклəндерү кагыйдəлəрен үтəү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һəм транспорт инфраструктурасы объектларына һəм күрсəтелə торган хезмəтлəргə ирешү мөмкинлеген тəэмин итү талəплəрен үтəү:

Үзəк, Мəктəп, Яшьлəр, асфальт, Сосна, Заречная, Югары, Вербная, Колотовка

урамнарында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү;

торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Үзәк, Мәктәп, Яшьләр, Асфальт, Сосна, Заречная, Югары, Вербная, Колотовка урамнары буенча юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту) ;
«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Писмән бистәсе, Гагарин урамы, 5 нче йорт, Иске Писмән бистәсе, Гагарин урамы, 1б йорт, Иске Писмән авылы, Үзәк урам, 50 нче йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.В.Насретдинов